**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 3 декабрендәге 4224 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 44 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:000000:37336, 16:50:000000:25617;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы: 16:50:250230;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: вакыты чикләнмәгән;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. Әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталарда күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 3 декабрендәге
4224 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




| Масштаб 1:500<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| (кызыл билге) | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| (зәңгәр контур) | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:250230 | кадастр кварталы |
| 16:50:000000:37336,<br>16:50:000000:25617 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |